| МИНИСТЕРСТВО ЗДРАВООХРАНЕНИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**26.08.2024** г. Казань **№ 1965**

Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау министрлыгының
2023 елның 28 ноябрендәге
№ 2844 боерыгына
үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Президентының «Федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссияләре турында» 2010 елның 1 июлендәге 821 номерлы Указына үзгәрешләр кертүгә бәйле рәвештә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссиясе турында нигезләмәне раслау турында» 28.11.2023 ел, № 2844 боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министры урынбасары В.С. Семеновага йөкләргә.»;

күрсәтелгән боерык белән расланган Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәдә:

1.3 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бирергә:

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба – дәүләт хезмәткәрләре, Министрлык) коррупциягә каршы тору максатыннан «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмый калу яисә җайга салу турындагы таләпләрне үтәүне тәэмин итүдән, бурычларны (алга таба – хезмәттәге тәртипкә карата таләпләр һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләр) үтәүне тәэмин итүдән;»;

2.4 пунктка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Килештерү гарызнамә алынган көннән алып 10 көн эчендә гамәлгә ашырыла.»;

3.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле «е» пунктчасы өстәргә:

«е) дәүләт хезмәткәренең аңа бәйле булмаган хезмәт тәртибе таләпләрен һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәүгә комачаулый торган хәлләр барлыкка килү турында хәбәрнамәсе.»;

3.4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«3.4.1. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» һәм «е» пунктчасының бишенче абзацында күрсәтелгән хәбәрнамә кадрлар хезмәтенең коррупцион һәм бүтән хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи заты тарафыннан карала, ул исә хәбәрнамәне карау нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән бәяләмә әзерли.»;

3.4.2 пунктында «3.1 пунктының «д» пунктчасында» сүзләрен «3.1 пунктының «д» һәм «е» «пунктчаларында» сүзләренә алмаштырырга»;

3.4.3 пунктында:

«а» пунктчасында «3.1 пунктының «д» пунктчасында сүзләрен» «3.1 пунктының «д» һәм «е» пунктчаларында» сүзләренә алмаштырырга.»;

«в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«в) әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында һәм «д» һәм «е» пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрне һәм хәбәрнамәләрне алдан карау нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән нәтиҗә, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 3.13, 3.15.1, 3.18, 3.18.1 пунктлары яисә башка карар кабул итү өчен тәкъдимнәр»;

3.7 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«3.7. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «д» һәм «е» пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамә, кагыйдә буларак, комиссиянең чираттагы (пландагы) утырышында карала.»;

3.8 пунктта «3.1 пунктының «б» пунктчасы» сүзләрен «3.1 пунктының «б» һәм «е» пунктчалары» сүзләренә алмаштырырга;

3.8.1 пунктының «а» пунктчасында «3.1 пунктының «б» пунктчасы» сүзләрен «3.1 пунктының «б» һәм «е» пунктчалары» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 3.18.1 пункты өстәргә:

«3.18.1. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «е» пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәренә бәйле булмаган хәлләр килеп чыгу һәм аның хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәү мөмкин түгеллеге арасында сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булуын танырга;

б) дәүләт хезмәткәренә бәйле булмаган хәлләр килеп чыгу һәм аның хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәү мөмкин түгеллеге арасында сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булмавын танырга.»;

3.19 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.19. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «а», «б», «в», «г», «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән мәсьәләләрне карау нәтиҗәләре буенча, шуңа сәбәпләр булганда комиссия әлеге Нигезләмәнең 3.11 - 3.15.1, 3.17 - 3.18.1 пунктларында каралганга караганда бүтәнрәк карар кабул итә ала. Нигезләр һәм дәлилләр комиссия утырышы беркетмәсендә чагылдырылырга тиеш.»;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясенең күрсәтелгән боерык белән расланган составын яңа редакциядә бирергә (кушымта итеп бирелә).

Министр М.М.Миңнуллин

Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау
министрлыгының
2023 елның 28 ноябрендәге
№ 2844 боерыгына
кушымта № 2
(Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау министрлыгы
26.08.2024 № 1965 боерыгы
редакциясендә)

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссиясе составы

Комиссия рәисе:

| | |
|---|---|
| Семенова Вера Сергеевна | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министры урынбасары |

Комиссия рәисе урынбасары:

| | |
|---|---|
| Фатыйхов Илдар Рәзин улы | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министры урынбасары |

Комиссия сәркатибе:

| | |
|---|---|
| Фәхретдинов Марат Хәмзә улы. | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының кадрлар бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Жирнова Галина Ивановна | «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбенең оештыру мәсьәләләре бүлеге башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| Лысенко Галина Викторовна | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Медицина эшчәнлеге стандартларын һәм сыйфатын тикшерү идарәсе башлыгы |

| | |
|---|---|
| Максимов Игорь Леонидович | «Казан дәүләт медицина университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең биомедэтика, медицина хокукы һәм медицина тарихы кафедрасы доценты, медицина фәннәре кандидаты (килешү буенча) |
| Мәхмүтов Чыңгыз Усман улы | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет рәисе, «РОССИЯ ӨЧЕН «ХАЛЫК ФРОНТЫ» Бөтенроссия иҗтимагый хәрәкәтенең Татарстан Республикасындагы төбәк бүлеге эксперты (килешү буенча) |
| Нәкыйпова Гөлнара Рафаэль кызы | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының кадрлар бүлеге башлыгы |
| Пологов Артур Олегович | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Фармация идарәсе башлыгы |
| Старостина Ирина Александровна | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы Эшләр идарәсенең гражданнарның хатлары һәм мөрәҗәгатьләре белән эшләү секторының әйдәүче консультанты, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының беренчел профсоюз оешмасы профсоюз комитеты рәисе |
| Фролов Дмитрий Николаевич | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Лицензияләү идарәсе башлыгы |
| Хәбибуллина Гүзәл Мөнип кызы | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Икътисадый анализ һәм фаразлау идарәсе башлыгы |
| Шрша Равия Бәдертдин кызы | Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Рәисе идарәсе вәкиле (килешү буенча) |
| Яруллина Эльмира Равил кызы | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының юридик бүлеге башлыгы |